ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОСИНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.40 лет Победы, 1, с.Осиново,
Зеленодольский район, 422527

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОСИНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Җиңүнең 40 ел ур., 1, Осиново ав,
Зеленодольск р., 422527

Тел.факс: (84371) 6-94-88. E-mail: Osin.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan.ru



**КАРАР**

№ 75

"19" апрель 2022г

«2022 елга Осиново авыл җирлеге башкарма комитетының «Осиново авыл җирлеге буенча торак хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 212 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы 156 статьясы (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милектне тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоткан өчен, күпфатирлы йортта хезмәт күрсәткән һәм гомуми милеккә идарә итү, карап тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 сентябрендәге 668/р номерлы боерыгы «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланучылар өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» (2017 елның 19 июнендәге 892/пр номерлы үзгәрешләр белән), Осиново авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Осиново авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 22 ноябрендәге 212 номерлы «Осиново авыл җирлеге буенча 2022 елга торак хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында» карарына 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме (НБ) квадрат метрдан 96,69 сум тәшкил итәчәк;

1.2. Җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Түләү коэффициенты (Кс) 0,071 күләмендә билгеләнгән»;

1.3. сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Шулай итеп, түләү коэффициенты белән наем өчен түләү күләме квадрат метрдан 6,86 сумга тигез".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә Осиново авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Осиново авылы (җирлек бинасы янәшәсендә), Осиново авылында Светлая

урамы, Юбилейная урамы, Пионерская урамы буенча Ремплер авылында, Коев урамы буенча Яңа Тура авылында Үзәк урамда, Яңа Тура урамында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

И.О. җитәкче
Башкарма комитет
Осиново авыл җирлеге

В.Е.Кондратьева